МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от 11 декабря 2024 года № 98

Казан ш.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигь булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» 2009 елның 30

декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) расларга.

2. Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә, хезмәткәрләргә, вазыйфалар исемлегенә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителгәндә, хезмәт яки гражданлык-хокукый килешүен төзегәндә гражданнарга йөкләнә торган, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясында каралган чикләүләр турында аңлатырга.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2023 елның 1 ноябрендәге 252 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Ф.М. Хәнифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының 2024 елның
«11» декабрендәге
№ 98 боерыгы белән расланды

Министрлыкта вазыйфа биләү коррупция куркынычына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары
ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

министрның беренче урынбасары;

министр урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфалары:

министр ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

эшләр идарәчесе;

транспорт идарәсе җитәкчесе;

стратегик үсеш идарәсе җитәкчесе;

автомобиль юллары идарәсе җитәкчесе;

финанс бүлеге җитәкчесе:

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге җитәкчесе;

юридик бүлек җитәкчесе;

режим, мобилизацияле әзерлек, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге җитәкчесе;

инфраструктура менюсы һәм дәүләти-хосусый партнерлык проектларын

гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе;

нормалаштыру һәм бәя кую бүлеге җитәкчесе.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

стратегик үсеш идарәсенең дәүләт сатып алулары секторы мөдире;

юл хәрәкәте иминлеге һәм автомобиль юллары идарәсенең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге секторы мөдире;

системалы администрацияләү һәм цифрлаштыру секторы мөдире;

объектларны террорчылыктан саклау секторы мөдире;

хезмәтне саклау һәм экологик куркынычсызлык секторы мөдире.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге җитәкчесе;

транспорт һәм тимер юл транспорты бүлеге җитәкчесе;

транспорт идарәсенең һава һәм су транспорты бүлеге җитәкчесе;

стратегик үсеш идарәсенең бюджетны планлаштыру бүлеге җитәкчесе;

стратегик үсеш идарәсенең тармак аудиты һәм предприятие эшчәнлеген анализлау бүлеге җитәкчесе;

автомобиль юллары идарәсенең автомобиль юллары бүлеге җитәкчесе;

транспорт инфраструктурасын үстерү һәм автомобиль юллары белән идарә итү федераль программалары бүлеге җитәкчесе;

оештыру үсеше бүлеге җитәкчесе;

оештыру эшләре бүлеге җитәкчесе урынбасары;

беркетмә һәм җыелма-аналитик эш бүлеге җитәкчесе;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

юридик бүлекнең әйдәп баручы киңәшчесе;

транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

транспорт идарәсенең тимер юл транспорты бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

транспорт идарәсенең һава һәм су транспорты бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

стратегик үсеш идарәсенең бюджетны планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

стратегик үсеш идарәсенең тармак аудиты һәм предприятиеләр эшчәнлеген анализлау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

автомобиль юллары идарәсенең автомобиль юллары бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

транспорт инфраструктурасын үстерү һәм автомобиль юллары белән идарә итү федераль программалары бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

системалы администрацияләү һәм цифрлаштыру секторының әйдәп баручы киңәшчесе;

инфраструктура менюсы һәм дәүләти-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

нормалаштыру һәм бәя кую бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

транспорт идарәсенең һава һәм су транспорты бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

стратегик үсеш идарәсенең бюджетны планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

стратегик үсеш идарәсенең тармак аудиты һәм предприятиеләр эшчәнлеген анализлау бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

автомобиль юллары идарәсенең автомобиль юллары бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

юл хәрәкәте иминлеге һәм автомобиль юллары идарәсенең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге секторының әйдәп баручы консультанты;

транспорт инфраструктурасын үстерү һәм автомобиль юллары белән идарә итү федераль программалары бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

инфраструктура менюсы һәм дәүләти-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

нормалаштыру һәм бәя кую бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

объектларны террорчылыктан саклау секторының әйдәп баручы консультанты.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

финанс бүлегенең әйдәп баручы белгече;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы белгече;

юридик бүлекнең әйдәп баручы белгече;

транспорт һәм тимер юл транспорты бүлегенең әйдәп баручы белгече;

стратегик үсеш идарәсенең дәүләт сатып алулары секторының әйдәп баручы белгече;

системалы администрацияләү һәм цифрлаштыру секторының әйдәп баручы белгече;

инфраструктура менюсы һәм дәүләти-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы белгече;

нормалаштыру һәм бәя кую бүлегенең әйдәп баручы белгече.

7. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

стратегик үсеш идарәсенең тармак аудиты һәм предприятиеләр эшчәнлеген анализлау бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

автомобиль юллары идарәсе автомобиль юллары бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

хезмәтне саклау һәм экологик куркынычсызлык секторының 1 разрядлы өлкән белгече.

---